# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

27.09.2016 № 14/2

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «җирле референдум турында»2004 елның 25 мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 статьялары, Иштирәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 1Мәләкәс авыл җирлегендә 2016 елның 20 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләргә.
2. Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Мәләкәс авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итәргә.

««2016 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 300 (өч йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 150 (йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Үзәк урамдагы Куаклы авылы буенча юлны ремонтлау - 16 950 сум.

- Иске Зирекле авылындагы Восточная урамындагы юлны ремонтлау - 39 000 сум

- Яңа Ерыклы авылындагы зиратка кадәрге юлны ремонтлау - 43 950 сум;

2) Ритуаль хезмәтләрне оештыру, күмү урыннарын карап тоту:

- Мәләкәс авылында зиратны коймалау өчен материаллар сатып алу - 231 950 сум;

- Мәләкәс авылы зиратын койма белән әйләндереп алу - 92 800 сум.

-зиратны коймалау өчен материаллар алу - 86 650 сум

- Иске Ерыклы авылында зират коймасын урнаштыру - 34 300 сум.

3) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлүне оештыру:

- Калинино авылындагы чишмәне төзекләндерү - 40 300 сум.

3. Референдум үткәрүне Тукай территориаль сайлау комиссиясенә, Мәләкәс авыл җирлеге участок сайлау комиссиясе йөкләргә.

4. Җирле референдум үткәрүгә бәйле чыгымнарны Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга

6. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар карар бастырылган көннән үз көченә керәә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе В.И. Артемьев